**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 гыйнварындагы 126 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 12 июлендәге 2216 номерлы «Идел буе районы Юлиус Фучик урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан электр челтәрләре – «Челтәрләр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 12 июлендәге 2216 номерлы «Идел буе районының Юлиус Фучик урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 ноябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы Федераль законның 3.6 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Җир кодексының V. 7 бүлегенә таянып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 12 июлендәге 2216 номерлы «Идел буе районы Юлиус Фучик урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**